

29нче январь конне Дубенка районы Ломат авылы мәчете бинасында «Толерантлык мисалы буларак Мордовия районнары» дигән темага зур чара vткән. Чамзинка һәм Дубенка районыннан торле милләтле яшьләрне бу чарада катнашырга чакырганнар. Очрашунын максаты да бvгенге жәмгыятьтә толерантлылыкнын ролен кvрсәтv бvлган. Кvпсанлы кvнаклар алдында дәрәжәле житәкчеләр белән бергә Мордовия районнары имамнары чыгыш ясаган. Алар бу юнәлештәге хезмәт унышлары белән уртаклашканнар.

Шул исптән Ломат мәчете имамы Раиль Мусин Чамзинка һәм Дубенка районы халкынын, биредә торле милләт һәм конфессия вәкилләренен дусларча гомер итvләре, яшьләрнен шул монәсәбәтләрдә яшәvләре турында мисаллар белән дәлилләп сойләде. Ул яшьләрне, бер-беребезне рухи, мәдәни якган баетып яшәргә, тагы да матур, дустанә монәсәбәтләрдә булырга чакырды. «Я привел в пример нашего Пророка Мухаммада, его взаимоотношения со своими соседями, исповедующими другие религии, и его великие нравственные качества, которых на сегодняшний день нам не хватает», - ди Раиль хазрәт Мусин аралашканда.

Чаранда мини-футбол буенча Дубенка районы житәкчесе иглан иткән турнирда II дәрәжә призы яулаган Ломат авылы яшьләре футбол командасына Рәхмәт хаты һәм бvләкләр тапшырганнар. Раиль Мусин сезоннын ин яхшы уйнаучысы Кисилёв Дмитрийга vз призын - Коръән (тәржемәдә) бvләк иткән; футболист аны укырга ышандырган. «Безнен командада, Ломат авылы командасында, берничә ел татарлар гына тvгел, ә рус һәм мордва милләтле спортчылар футбол уйныйлар. Алар бер-берсен ихтирам итәләр; командада дуслык яши. Менә бvгенге чарага да болельщиклары белән бергә килгәннәр. Шулай булырга тиеш тә», - ди алар турында әнгәмәдәшем.